**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сораулары җаваплары (муниципаль тур, 2021-2022 уку елы) 7 нче сыйныф**

**Максималь балл – 53**

I. Лирик әсәргә караган биремнәр (24 балл).

***Мине шагыйрьлектә мәңге тугры ит, Тәңрем;***
***Шунда гына күңелемнең бөтен теләк-омтылышы.***

1. Бу шигырь юлларының авторын һәм шигырьнең исемен язып куй (4 балл). *Авторы*: **Габдулла Тукай**, *шигырьнең исеме*: **Милләткә**

2.Әлеге шигырьдә лирик герой нинди хыялы, максаты турында сөйли? Җавабыңны биш-алты җөмлә белән яз (6 балл).

**Шигырьдә лирик герой бар гомерен шагыйрьлеккә багышларга, гомере чикләнгәндә дә шагыйрьлек данын югалтмаска тели. Аның бар теләге-омтылышы тырышлыгы бушка китмәү, милләтенең аның халыкы өчен булган тырышлыкларын аңлавы, аңа илтифат күрсәтүе. Үзе үлгәнннән соң да халык күңелендә исеме яшәү, халыкның аның мәхәббәтен бәяләүе лирик герой өчен зур бәхет булачак. ул шуны өметләнә, шул хакта хыяллана да.**

3. Шигырьдә лирик герой хисләренең сәбәбен күрсәт (4 балл): **милләтенә булган чиксез ярату, мәхәббәт.**

4. Шигырьнең төп идеясен язып куй (5балл): **иң зур бәхет – үз милләтеңә хезмәт итү һәм милләтнең аны югары бәяләве.**

5. Бу шигырь лириканың кайсы жанрына карый? (5 балл). Җавабыңны яз: **гражданлык лирикасы**

II.Эпик – әсәрләргә караган биремнәр. Үзең теләгән **бер вариантны гына** сайлап эшлә (16 балл).

**I вариант**

*Бераз баргач, уң якта бердән чытырдаган тавышка сискәнеп китеп, куркуыннан кире чабарга башласа да,чыпчык очып чыкканнан агач яфрагы гына чытырдаган икәнен белгәч, тагын кире килде. Әнисе аны җен-пәри юк икәненә ышандырган булса да, бакча эчендә бүре-фәлән булуы мөмкинлеген ул исеннән чыгармый иде. Чөнки ул бакчаның кайларга-кайларга барып чыкканын белми, бары бу юлның озакламыйча бер чәчәклеккә чыгачагын, ул чәчәклектә чәй эчәр һәм утырыр өчен урыннар барлыгын гына белә.*

1.Әлеге өзек нинди әсәрдән алынган? Аның авторы кем? (4 балл).

Әсәрнең исеме: **Яшь ана**, авторы: **Нәҗип Думави**.

2.Әсәрнең төп герое кем? (2 балл): **Заһидә**

3.Бу әсәр нинди жанрга карый? (4 балл) **Хикәя**.

4.Әсәрнең жанрына хас үзенчәлекләрне аңлатып бир (төшенчәгә аңлатма яз) (6 балл).

**Хикәя – кече эпик жанр. Катлаулы булмаган вакыйганы, кешенең билгеле бер сыйфатын ача. Катнашучылар сан ягыннан чикләнгән була. Тормышның аерым бер мизгелен генә сурәтли. Автор тел бизәкләренә, символларга, тәэсирлелеккә игътибар итә.**

**II вариант**

*Хәзер инде көймә булдыксыз, кызганыч ябалак кебек түгел, йөрәкле карчыга шикелле матур һәм сөйкемле күренә иде. Көймәдәге егетләр дә көчсез һәм йомшак тараканга түгел, гайрәтле үткен кырмыскаларга охшый иде.*

*Гөрләвек дулкыннар арасында зирәк кош кебек оча-калка килгән көймә, көчле бер дулкын селтәве белән кырыйга үрләшеп, шып итеп туктады. Арттан килгән дулкыннар да инде аны кузгатып ала алмый иделәр.*

1.Әлеге өзек нинди әсәрдән алынган? Аның авторы кем? (4 балл).

Әсәрнең исеме:**Акчарлаклар**, авторы: **Шәриф Камал**

2 Әсәрнең төп герое кем? (2 балл). **Гариф**

3.Бу әсәр нинди жанрга карый? (4 балл) **Повесть**

4Әсәрнең жанрына хас үзенчәлекләрне аңлатып бир (төшенчәгә аңлатма яз) (6 балл).

**Повесть – эпик жанр. Хикәядән күләмлерәк, анда вакыйгалар, геройлар язмышы тирәнрәк, киңрәк ачыла. Сюжет сызыгы тармаклы, проблемалар да катлаулырак. Вакыйгаларның урыны һәм вакыты да киңрәк колачлы булуы белән характерлы.**

III.Тестларга җавап бир (3 балл)

1.Күрсәтелгән әсәрләрнең авторларын әсәр исеме белән янәшә язып куй (1 балл).

а) «Сандугач һәм чишмә» – **Муса Җәлил**

б) «Шундый минем туган ягым» – **Роберт Миңнуллин**

в) «Имче» – **Рабит Батулла**

2. «Беренче театр» әсәренең авторын билгелә (1балл).

а) Ибраһим Гази

б) Әхмәт Фәйзи

в) **Галиәсгар Камал**

3.«Идегәй» әсәренең жанрын күрсәт (1балл).

а) поэма

б) **дастан**

в) баллада.

IV. Иҗади бирем (10 балл).

«Чын дуслык нинди була» дигән темага инша яз. Фикерләреңне Һади Такташның «Мокамай» һәм Галимҗан Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр»

әсәрләрендәге геройлар язмышы ярдәмендә дәлиллә. Бирелгән мәкальләрне урынлы итеп куллан.

*Дуслык – зур байлык.*
*Кош канаты белән, кеше дуслык белән көчле.*
*Дус дус өчен мал бирер, яу килгәндә җан бирер*.

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сораулары җаваплары (муниципаль тур, 2021-2022 уку елы) 8 нче сыйныф**

**Максималь балл – 50**

I. Лирик әсәргә караган биремнәр (19 балл).

1. Шигырь юлларын укы, бу юлларның авторын һәм кайсы шигырьдән булуын күрсәт (4 балл):

а) *Укыйм тиз-тиз күңелдән гаҗәиб сурә Коръәннән*
*Газаплар мәгънәви бер кул илән алынадыр җаннан.*

Авторы: **Габдулла Тукай**, шигырьнең исеме: **Тәәссер**.

ә) *Кыйл дога, ихлас белән тезлән дә кыйбла каршына;*
*Бел аны: керсез күңелдән тугъры юл бар гаршенә.*

Авторы: **Габдулла Тукай**, шигырьнең исеме: **Таян Аллага**.

2. Биш-алты җөмлә белән бу шигырьләрнең лирик героеларына хас булган уртак хис-кичерешләрне тасвирлап яз (6 балл) .

**Габдулла Тукайның ике шигырендә дә лирик герой Аллага ышануның кеше рухына көч, максатына ирешүдә юл күрсәтүен сөйли. Аллага ышану күңеленә ышаныч бирә, сафландыра, газаплардан арындыра, Коръән сурәсен укудан яңадан туган кебек чистарынып кала. Шуның өчен лирик герой Аллага ышанырга, таянырга, тугры юл күрсәтүне аннан сорарга куша.**

3. Әлеге ике шигырьгә дә уртак булган идеяне яз (5 балл):

**Коръән юлыннан тайпылмау тормыш авырлыкларыннан саклый //Күңелеңнән яхшылыкка омтылу, яхшы теләктә булу һәм аңа ышану кешене бәхеткә илтә.**

4.Шигырьләр лириканың кайсы жанрына карый? (4 балл).

**күңел лирикасы // интим лирика.**

II. Эпик – әсәрләргә караган биремнәр. Үзең теләгән **бер вариантны гына** сайлап эшлә (18 балл).

I вариант

Өзекне укы һәм сорауларга җавап яз.

*Ярты төн узган, эшле, эшсез йоклый, ял итә, әмма бала һаман елый иде. Биш-ун минут туктап тора, тагын елый башлый...Бишеге янында зыр катып юатыр өчен газапланган анасы, бигрәк тә ире белән кунак тынычлап йоклый алмый торганнардыр дип борчыла.*

*Чыннан да, кунак йокламый иде.*
1. Әсәрнең исеме (2 балл): **Буранда**;
2. Әсәрнең авторы (2 балл):**Шәриф Камал**;
3. Әсәрнең жанры (2 балл):**Хикәя**;
4. Әсәрнең төп герое (2 балл):**Мостафа**;
5. Төп геройның кичерешләре һәм бу кичерешләрнең сәбәпләрен аңлатып яз (6 балл)

**Әсәрнең төп герое Мостафа күңел газаплары кичерә, анасы янына ашыга, сызлана, үз-үзенә урын таба алмый, үзен битәрли, үкенә, үз гамәлләрен кичерә алмый, үзен акларлык сәбәпләр тапмый. Бу хисләрнең сәбәбе: төнлә елаган бала һәм аның бишеге янында төн үткәргән ананы күрү. Бу күренеш Мостафага үзенең сабый вакытын, анасының күз яшьләрен, үзенең дә анасын рәнҗетүен, аннан гафу үтенмәвен, озак еллар аның хәлен белми, аның янына кайтмый яшәвеннән туа.**

1. Төп геройның кичерешләрен автор нинди алымнар ярдәмендә ача? (4 балл)

**Импрессионизм, экзистенциализм(сызлану фәлсәфәсе кеше психологиясен тирәнтен ачу) белән үрелеп бара.**

II вариант

Өзекне укы һәм сорауларга җавап яз.

*Мин, мондагы күренештән арып, җаным, күңелем белән арып, шул эскәмиянең әле җимерелеп өлгермәгән башына барып утырдым да иске хатирәләремне башыма җыймакчы булдым. Эскәмия артындагы карт агачтан, ни өчендер гаркылдашып, каргалар таралдылар; алар, үзләренең колакларны газаплый торган ямьсез тавышлары белән бөтен бакчаны тутырып, минем баш очымда әйләнеп йөри башладылар. Агачтан минем өскә әллә нинди чүпләр коелдылар.*

*Кайчандыр бу агачның ботакларында сандугачлар сайрыйлар иде!*

1. Әсәрнең исеме (2 балл):**Бер хәрабәдә;**

2. Әсәрнең авторы (2 балл):**Фатих Әмирхан;**
3.Әсәрнең жанры (2 балл):**Хикәя;**
4. Әсәрдә вакыйгалар кем исеменнән сөйләнә? (2 балл): **Хикәяләүче «мин»;**
5. Хикәяләүченең кичерешләре һәм бу кичерешләрнең сәбәпләрен аңлатып яз (6 балл).

**Хикәяләүче тормыштагы үткән һәм бүгенгене чагыштыра, биш ел эчендә булган зур үзгәрешләр, аның җимергеч тәэсирен күреп гаҗиз кала, аптырый, үз-үзенә урын таба алмый. Вакытның бар нәрсәдән өстен булуы, биш ел эчендә чәчәккә, шатлыкка күмелеп яшәгән бәхетле гаилә**

**тормышыннан җимереклек, хәрабәләр генә торып калганын күрү аны сызландыра, әрнетә:**

**– Ләгънәт сиңа, и тормыш! Әвәл алдыйсың, аннан соң мыскыллыйсың! – ди ул.**

2. Төп геройның кичерешләрен автор нинди алымнар ярдәмендә ача? (4 балл)

**Импрессионизм фәлсәфи фикер җиткерү һәм экзистенциализм(сызлану фәлсәфәсе) белән үрелеп бара.**

III.Тестларга җавап бир (3 балл).

1.Күрсәтелгән әсәрләрнең авторларын әсәр исеме белән янәшә язып куй(1 балл).
а) «Әйтелмәгән васыять» – Әмирхан Еники
б) «Җан Баевич» – Гаяз Исхакый
в) «Театр» – Габдулла Тукай
2. «Язмышның туган көне» әсәренең авторын билгелә (1балл).
а) **Галимҗан Гыйльманов**
б) Әхмәт Фәйзи
в) Галиәсгар Камал
3.«Әни килде» әсәренең жанрын күрсәт (1балл).
а) повесть
б) **драма**
в) баллада

IV. Иҗади бирем (10 балл).

Чын кеше булу өчен нинди сыйфатларга ия булу кирәк? Әлеге сорауга үзеңнең фикерләреңне яз. Җавабыңа нигез буларак Мөхәммәдьяр, Габдулла Тукай һәм Мәҗит Гафуриларның бер үк исем белән аталган «Нәсыйхәт» шигырьләрендәге фикерләргә таян һәм бирелгән мәкальләрне урынлы итеп файдалан.

*Җаның олы булса, һәр эшең олы.*
*Кеше булу кыен түгел, кешелекле булу кыен.*
*Күңел ярлылыгы кесә ярлылыгыннан начаррак.*

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сораулары җаваплары (муниципаль тур, 2021-2022 уку елы) 9 нче сыйныф**

**Максималь балл – 43**

I. <u>Әдәбият теориясенә караган бирем (18 балл).</u>

Урта гасырлар әдәбияты нинди чорларны үз эченә ала? Эзлекле итеп, һәр чорның исемен яз. Бу чорларга ни өчен шунды исем бирелгәнлеген аңлат (10 балл) Саналган иҗат әһелләрен – *Котб, Мөхәммәдьяр, Кол Гали, Мәүлә Колый* – үзләре иҗат иткән чорга тәңгәл китереп язып куй (4 балл). Бу авторларның берәр әсәренең исемен яз (4 балл)

**1.Болгар-Хәзәр чоры – Кол Гали. «Кыйсаи Йосыф»**
**2. Алтын Урда чоры – Котб. «Хөсрү вә Ширин»**
**3.Казан ханлыгы чоры – Мөхәммәдьяр. «Нуры содур»**
**4.Торгынлык чоры – Мәүлә Колый. «Хикмәтләр»**

<u>II Укылган әсәр турында фикерләү (12 балл)</u>

Заһир Бигиевнең «Меңнәр, яки Гүзәл кыз Хәдичә» әсәренең геройлары Муса Салихов яки Габеннасыйр образларына чагыштырма характеристика яз. Аларда мәгърифәтчелек әдәбиятына хас үзенчәлекнең чагылышын күрсәт.

**Муса Салихов Петербургта университет тәмамлаган, этисенең эшен дәвам итүче сәүдәгәр, 25 – 26 яшьләрендә, өйләнмәгән. Әхмәди байның Хәдичә исемле кызын яраткан.**

**Габденнасыйр да гимназия курс тәмам иткән, 23 – 24 яшьләрдәге егет. Ул да Әхмәди байның Мусага ярәшелгән кызына өйләнергә тели.**

**Муса әфәнденең өйләнүе акчага, кызның бирнәсенә кызыгудан түгел. Ә Габденнасыйрны кызның мең сумлык бирнәсе кызыктыра. Ул максатына ирешү өчен төрле явызлыкларга бара, ялган юлына баса. Мусаны кеше үтерүдә гаепле, төрмәгә утыруына сәбәп була. Әсәрдә Габеннасыйр мәкерле, явыз, үз максатларына әшәкелек белән ирешүче тискәре герой. Муса, киресенчә, йомшак күңелле, тугъры сүзле, гадел һәм укымышлы зат итеп бирелә.**

**Геройларның әхлакый яктан бер-берсенә капма-каршы булулары, уңай һәм тискәре герой булып төгәл аерылып торулары мәгърифәтчелек әдәбияты кануннары белән аңлатыла.**

<u>III.Тестларга җавап бир (3 балл)</u>

1.Күрсәтелгән әсәрләрнең авторларын әсәр исеме белән янәшә язып куй(3 балл).

а) «Сүнгән йолдызлар» – **Кәрим Тинчурин**

б) «Туган ягым – яшел бишек» – **Гомәр Бәширов**

в) «Сибәли дә сибәли» – **Фатих Кәрим**

2. «Әлдермештән Әлмәндәр» әсәренең авторын билгелә (1балл).

а) Фәнис Яруллин

б) **Туфан Миңнуллин**

в) Аяз Гыйләҗев

3.«Җилкәннәр җилдә сынала» әсәренең жанрын күрсәт (1балл).

а**) повесть**

б) поэма

в) комедия

**IV**.Иҗади бирем (10 балл)

*Гадел белән, бу җиһан төзек булыр,*
*Гадел белән дөнья тулы нур булыр.*

Мөхәммәдьяр иҗатына нисбәтле бу шигырь юлларның мәгънәсен аңлатып, тормышта гаделлекнең әһәмияте турында үз фикерләрене белдереп инша яз.Бирелгән мәкальләрне иншаңда урынлы итеп файдалан.

*Гадел кеше абынмас.*
*Гаделлекне ир дә ил дә хөрмәт итә.*
*Гаделлек юк җирдә, адәмлек булмас.*

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сораулары җаваплары (муниципаль тур, 2021-2022 уку елы) 10 нче сыйныф**

**Максималь балл – 43**

I. Әдәбият теориясенә караган бирем (15 балл).

Әдәбият белеме фәненең тармакларын ата. Аларның һәркайсысына кыскача аңлатма бир.

Әдәбият белеме өч тармакны үз эченә ала:

**әдәбият теориясе – әдәбият төзелеше һәм үсешенең гомуми законнарын өйрәнә;**

**әдәбият тарихы – әдәбиятның үткәнен процесс яки бу процессның аерым бер тарихи киселешендә (аерым чорны алып) тикшерә;**

**әдәби тәнкыйть – иҗтимагый һәм әдәби күзлектән чыгып, хәзерге һәм үткән дәверләр әдәбияты мәсьәләләре белән шөгыльләнә. Гомум әдәбият кануннарына, һәм үз чорының идея-эстетик таләпләренә нигезләнеп, әдәби әсәрләргә бәя бирә.**

II. Укылган әсәр турында фикерләү ( 15 балл)

Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» яки Сәйф Сараиның «Сөһәйл вә Гөлдерсен» поэмаларының берсенең идеясен күрсәт. Әсәр идеясен укучыга җиткерүдә автор кайсы геройларга һәм нинди вакыйгаларга нигезләнүен яз.

**1. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы төп идея Коръән һәм гомумкешелек идеалын ачып бирә. Кеше никадәр камилрәк булса, ул үзен дә һәм янәшәсендәгеләрне дә бәхетле итүгә шулкадәр якын тора. Кеше һәр кылган гамәле өчен иртәме-соңмы җавап тота. Әлеге идея Ягъкуб пәйгамбәр гаиләсе язмышындагы вакыйгалар ярдәмендә ачыла (укучы киңрәк, тәфсилләп, мисаллар белән язар, билгеле).**

**2. Сәйф Сараиның «Сөһәйл вә Гөлдерсен» поэмасында кешелеклелек (гуманистик) идея өстенлек итә. Явызлык, җимергеч сугыш, коллыкка саф мәхәббәт, тугрылык каршы куела. Автор дөньяны золымнан азат итәргә, фаҗигаларны туктатырга чакыра. Мәхәббәтнең дошманлык көченнән өстенлеген раслый. Явызлык хәкимлек иткәндә саф хисләрнең үлемгә дучар булуын дәлилли. Бу Сөһәйл һәм Гөлдерсен язмышы аша ачып бирелә.**

<u>III.Тестларга җавап бир(3 балл).</u>

1.Күрсәтелгән әсәрләрнең авторларын әсәр исеме белән янәшә язып куй( балл).

а) «Кайсыгызның кулы җылы» – Хәсән Туфан

б) «Калдыр, аккош, каурыеңны» – Илдар Юзиев

в) «Җомга көн, кич белән» – Аяз Гыйләҗев

2. «Таң җиле» әсәренең авторын билгелә (1балл).

а) Туфан Миңнуллин

б) **Фоат Садриев**

в) Аяз Гыйләҗев

3.«Итил суы ака торур» әсәренең жанрын күрсәт (1балл).

а) поэма

б) дастан

в) **тарихи роман**

<u>**IV.Иҗади эш (10 балл)**</u>

*Гәүһәр – таш ул, ләкин һәр таш гәүһәр булмас,*
*Тикмә кеше (акылы булмаган) кеше гәүһәр кадрен белмәс* (Кол Гали).

бу шигырь юлларның мәгънәсен аңлатып, бу уңайдан үз фикерләрене дә белдереп инша яз. Иншада түбәндә бирелгән мәкальләрне дә урынлы итеп файдалан.

*Яманны күрмәс борын, яхшыны танып булмас.*
*Юләр зурны, акыллы затлыны күзләр.*
*Һәр ялтырган алтын, һәр өйрәткән остаз түгел.*

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сораулары җаваплары (муниципаль тур, 2021-2022 уку елы) 11 нче сыйныф**

**Максималь балл – 50**

I. Әдәбият теориясенә караган бирем (21 балл).
Әсәр сюжетның элементларын санап чык, аларны аңлатып яз. Фатих Хөснинең «Йөзек кашы» әсәре мисалында сюжет элементларын күрсәт. (Сюжет исемен атаган өчен 1 балл (алар 7), һәркайсын дөрес аңлатканга 1 балл, димәк 7 балл; әсәр мисалында дөрес күрсәткән өчен 1 әр балдан 7 балл)

**Пролог** – әсәрдә сөйләнәчәк тарихтан элек булган вакыйгаларны сөйләү.

**Экспозиция** – конфликтны барлыкка китерүче сәбәпләр, геройлар, вакыйгалар барачак урын белән таныштырып кую. (Айдар, гаиләсе, аның авылдашлары, Вәсилә белән тагыныштыра)

**Төенләнеш** – конфликтның барлыкка килү урыны. (Вәсилә Айдарга алма ыргыта, Госманның моның белән килешәсе килми.)

**Вакыйгалар үстерелеше** – конфликтның үсү-үзгәрүе. (Госман белән Айдар сабантуйда ат чабышында катнаша. Госман Айдарның атына, Айдар Госманның битенә камчы белән суга)

**Кульминацион нокта** – конфликтның иң югары ноктасы. (Айдар туй ясый, Госман Айдарның кәләше Вәсиләгә яла яга. Айдар Вәсиләне калдырып авылдан китеп бара.)

**Чишелеш** – конфликтка нокта куелу, аның юкка чыгуын яки чишелә алмаслыгын күрсәтү. (Айдар сугыш кырында Госманны очрата, аның хыянәтче булуына ышана.)

**Эпилог** – соңгы нәтиҗә, геройларның әсәрдә сурәтләнгән вакыйга - хәлләрдән соңгы язмышлары турында хәбәр итү. (Автор Вәсилә белән очраша, әсәр камаулы композиция ярдәмендә тудырылган.)

II. Укылган әсәр турында фикерләү (16 балл)

Муса Җәлилнең «Табут» шигырен хәтереңә төшер һәм сорауларга җавап бир.
а) «Табут» сюжетлы шигырь була аламы? Ни өчен? Дәлилләп бир.
**Муса Җәлилнең «Табут» әсәре сюжетлы шигырь була ала. Әлеге шигырь юмористик вакыйганы сюжет буларак оештырган әсәр һәм шул вакыйгага мөнәсәбәтле туган хис-кичерешләрне сөйли.**

б) Шигырьдәге каршылыкларны билгелә?
**Картлык һәм яшьлек; өметсезлек һәм өмет; яшәү яме һәм үлем; һ. б.**
в) Шигырьнең идеясен аңлатып яз. Ул нинди геройлар ярдәмендә ачыла?
**Матурлык, күңел җылысы, бер җылы караш һәм юмор хисе яшәү көче бирә, өмет өсти, үлемне кичектерә. Фарук һәм яшь кызның әңгәмәсе мисалында ачыла.**
г) Фарук картның табут ясатырга баргандагы һәм яшь кыз белән очрашканнан соңгы хис-кичерешләрен кузаллап тасвирлап яз.
**Фарук картның табут ясатырга килгәндә язмыш белән килешүе, үлемне тыныч, гадәти итеп кабул итүе, күңел төшенкелеге, өметсезлеге һ.б кичерешләре ачыла. Яшь кыз белән очрашканнан соң авыр тойгалардан арына, аның шаянлыгына мут җавап биреп, тормышка өмете, яшәү дәрте уяна.**

<u>III.Тестларга җавап бир(3 балл).</u>

1.Күрсәтелгән әсәрләрнең авторларын әсәр исеме белән янәшә язып куй(1 балл).
а) «Таң вакыты» – **Сәгыйть Рәмиев**
б) «Көз» – **Гаяз Исхакый**
в) «Галиябану» – **Мирхәйдәр Фәйзи**
2. «Яшь йөрәкләр» әсәренең авторын билгелә (1балл).
а) Ибраһим Гази
б) **Галимҗан Ибраһимов**
в) Габдулла Тукай
3.«Идел» әсәренең жанрын күрсәт (1балл).
а) поэма
б) дастан
в) **повесть**

<u>IV.Иҗади бирем (10 балл)</u> «Ни сәбәптән җир йөзендә тәнгә – мунча, җанга – юк?!» Габдулла Тукайның әлеге шигырь юлларын эпиграф итеп алып, «Күңелеңә кер кунмасын дисәң...» дигән темага инша яз. Бирелгән мәкальләрне тиешле урында файдалан.
*Күңелнең ак булса, намусың саф булыр.*
*Күлмәкне яңа вакытында, намусыңны яшьтән сакла.*
*Ак күңелнең аты армас, туны тузмас.*